
С. МАРШАК



С. МАРШАК

Мистер Твистер



Ҡ. Нәҗми һәм *Х. Ҡамалов* тәрҗемәсе

ТАТАРСТАН ҠИТАП НӘШРИЯТЫ
Ҡазан 1960



КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН

Самуил Яковлевич Маршак

МИСТЕР ТВИСТЕР

(на татарском языке)

Редакторы *Р. Н. Даутов*

Художник *Е. П. Старостин* рәсемнәреннән күчермә

Художество редакторы *Х. Ш. Әхмәтҗанов*

Техник редакторы *Р. С. Нәбиуллина*


Корректоры *Н. Г. Рәхимкулова*


Производствога бирелде 27|XI-59 ел. Басарга кул куелды 26|III-60 ел.
Кәгазь форматы 70x92¹|₁₆. Учет.-изд табак 1,78. Басма табак 2,25(2,63).
Табакта 34400 знак. Заказ № К-573. Тираж 25000 экз. Бәясе 60 тиен.

Татарстан Культура министрлыгы каршындагы нәшрият һәм полиграфия промышленносте бүлегенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, 19. 1960 ел.

1

Кукның
Конторы
Бар, ди,
Чит илдә.
Эчегез пошып
Сезнең әгәр дә
Булса барасы
Берәр җиргә —
Таити утравына,
Парижга,
Яки очып
Памир тавына, —
Шул минуттук
Сезнең өчен
Кук
Хәзерләтер
Кораб каютын,
Я җибәртер
Һава көймәсен,
Иярләтер
Атын,
Дөясен.
Урнаштырыр
Яхшы отельгә,
Иртәнге аш
Бирелер постельгә.
Урманнар һәм таулар арасын,
Чикләвек һәм пальма агачын,







Җирнең җылы,
Салкын якларын, —
Күк күрсәтер сезгә ни барын.

2

Мистер
Твистер —
Булмыш министр,
Мистер
Твистер —
Банк иясе,
Пароход, завод,
Газет хуҗасы, —
Байлыгы бик мул!






Эч пошудан бер
Илләр гизәргә,
Диңгез кичәргә
Карар итте ул!



— Их, шәп! —
Дип кызы
Шатланып әйтә: —
Совет иленә
Барыйк без, әйдә!
Ашармын анда
Кызыл икралар,
Бөртек икралар,
Тотармын тере
Осетралар,
Волга бозында
Тройкаларда
Утырып чабырмын,
Ә колхозларга
Җиләккә барырмын!
— Дустым, бик сәер
Теләгең синең, —
Диде әтисе, —
Ник Советларга
Сиңа барырга?
Барыйк Даниягә,
Швециягә,
Барыйк Неапольгә,
Барыйк Багдадка!
— Юк! — диде кызы, —
Телим барырга
Ленинградка!
Кызның таләбе —
Закон мистергә,
Тиеш берсүзсез
Ул үтәлергә!




3

Шул ук минутта
Кукка
Телефон аша
Твистер эндәшә:
— Дүрт кают кирәк
Нью-Йорктан
Ленинградка!
Ванналы,
Заллы,
Фонтан,
Бакчалы
Номер алсыннар.
Тик карасыннар:
Негр,
Кытайлар
Була күрмәсен
Анын күршендә.
Мистер
Аларның
Сөйми берсен дә.
Кук
Телефоннан
Белдерә:
— Ярый!
Теләкләрегез
Үтәлер бары.







4


Ķораб китәргә
Ун минут
Ķалгач,
Твистер килде.

Янында —
Ķартлач
Хатын күренде,
Күзлек кигән ул.
Ķызы да шунда:
Аның кулында —
Бәләкәй маймыл.

Алар артыннан
Дүрт егет килә,
Егерме дүрт зур
Чемодан белән.

5

Пароход йөзә
Яшел диңгездә,
Америкадан
Килә ул безгә.



Көнчыгышка ул
Туп-туры бара.
Кораб кырында
Океан
Чайкала.
Мистер
Твистер —
Булмыш министр,
Мистер Твистер —
Банкир,
Байгура —
Океан өстендә
Туп уйнап бара.
Пароходта бар
Теннис мәйданы —
Җәтмәләр белән
Корганнар аны.
Куркыныч түгел
Һич Твистергә,
Кулында суккыч, —
Чаба, йөгерә...
Көн кызу чагы —
Төшлек җиткәчтен,

Уеннан туеп,
Арып беткәчтен,
Ҡерешә тагы
Биллиард уйнарга:





Сөяк шарларны
Озын ки белән
Тотына куарга.

Океан чайкала,
Дулкын чалара,
Күп катлы йорттай,
Пароход-сарай
Тиз алга бара!

Якын тирәдә
Ҡара тәнлеләр:

Негр,
Кытайлар
Һәм башка шундый
Төрле халык юк, —
Негр,
Кытайны
Һәм башкаларны
Дулкында чайкый
Бүтән пароход.
Аларга кайда
Рәхәт бу төсле?
Негр, кытайга
Юеш һәм эссе, —
Морҗадан чыга
Төтен кап-кара,
Өскә тозлы су
Дулкын актара.





6


Мистер Твистер —
Миллионер.
Совет илендә
Турист ул хәзер.

Ленинград порты
Шаулый
Ерактан.
Шәһәр йортлары
Балкый
Уң яктан.
Сулары соргылт,
Колоннасы таш,
Завод төтене —
Корым аралаш.

Эшләпә читен
Тотты да,
Мистер
Траптан йөгереп
Чыкты:
Пристань.



Петропавелның
Гөмбәз башына
Күз төшергәнче,
Килде машина.
Төялде әйбер,
Ханымнар менде.
Автомобиль бер
Усал үкерде —
Алга омтылып,
Выжлап бар хәлгә,
Һәм алып китте
Асфальттан, өреп
Бензин сулышын
Җәяүлеләргә.





7

Мистер
Твистер —
Булмыш министр,
Мистер
Твистер —
Миллионер,
Завод, пароход,
Газет хуҗасы —
Кунак өенә —
«Англетер»гә
Килеп керде дә
Сорады номер.
Алтын сигара
Авызында көйри,
Швейцар белән
Инглизчә сөйли:
— Бармы номерлар
Сезнең отельдә,
Кичә үк сезгә
Хәбәр ителде.




Мыеклы абзый
Җавап бирә:
— Бар!
Тугыз белән ун —
Сезнең номерлар:
Өченче катта,
Беренче бүлмә,
Багажлар шунда
Илтелер сезгә.

Швейцар бара,
Кунаклар аңа
Барсы да ияргән:
Твистер, хатыны
Һәм атлый кызы, —
Маймыл күтәргән.
Алар керделәр
Көзгеле лифткә.
Ал, сары утлар
Кабынып китә.
Мистер гаиләсен
Ул өскә илтә...


8

Көзгеләр яныннан
Номерга табан
Үттеләр алар
Хәтфә паластан.

Швейцарында —
Укалы кием.
Аның артында —
Панама киеп,
Атлый юлчыбыз.
Аның артында —
Күзлекле хатын,
Ияргән тагын
Маймыл тоткан кыз.



Кинәттән юлчы:
— Йа хода! — диде.
Шаккатты шунда
Хатыны, кызы,
Баскыч буенча
Бер кара тәнле
Барган чагында
Кырыйдан узып.



Йөз туксанынчы
Номердан
Төшеп
Килә
Зур буйлы,
Кап-кара
Кеше.

Баскычны тоткан
Кулы
Кап-кара.
Трубка тартып,
Ашыкмый бара.

Күзгедә күренә:
Әллә нихәтле
Кара негрлар,
Кара кешеләр,
Төсләре белән,
Йөзләре белән
Берсе-берсенә
Охшаш ишеләр.

Түбән төшәләр —
Һәркайсы
Баскыч
Кырыен тоткан,
Һәркайсы
Авызына
Трубка
Капкан.

Мистер
Ачуын
Йота алмады.
Уңга
Қаранды,
Сулга
Қаранды...
— Қиттек! — дип дулый
Хатыны, кызы: —
Әйдәгез, тизрәк
Бирeдән сызыйк.
Қара негрлар
Торган чагында,
Бер минут та без
Қалмыйбыз монда!








Панамлы юлчы,
Эре-эре
Атлап,
Йөгерә
Баскычтан
Түбәнге
Катка.
Артта —
Карчыгы,
Күзлек кигән ул,
Артта —
Теге кыз,
Кулында маймыл.



Кызып, автога
Алар утырды.
Маймыл койрыгы
Ялгыш кысылды.
Швейцар, чыгып,
Саубуллашты да
Телефон аша
Кычкырды шунда:
— Унбиш — нуль — унбиш,
Һәм өч йөз тагын...
Бирегез миңа
«Турист» конторын.
Сезгә әйтәм мин
Әйбәт бер хәбәр:
Кунаклар килсә,
Безгә дә җибәр.
Ике бүлмә буш —
Ванналы, заллы...
Көтеп торабыз
Без юлчыларны!..

9

Өерә урамда
Тузаннарны җил,
Йөгерә урамда
Бер автомобиль.



Шофер янында
Мистер утыра,
Күн мендәрләрдә
Тирбәлеп бара.
Тыңлый көпчәкнең
Җитез выжлавын,
Күрә тәрәздә
Нурлар уйнавын.

Арткы урында —
Кызы, карчыгы,
Беткәннәр алар
Тәмам талчыгып.

Ал вуальләрен
Җилләр уйната...
Инде кич булган, —
Кояш та бата.



Гоголь урамы,
Өченче капка.
— Килдегез, — диләр. —
Бүлмә юк чакта.

Пестель урамы,
Беренче капка.
— Килдегез, — диләр, —
Урын юк чакта.

Ирек мәйданы,
Бишенче капка.
— Бүлмә юк, — диләр, —
Бездә бу чакта.
Кеше күп килде
Съездга бүген,
Тик бер бүлмә дә
Хәзер буш түгел!



Шартлап ярылды
Уң яктагы
Шин,
Җитмәстер, ахры,
Моторга
Бензин.

10

Мистер
Твистер —
Булмыш министр,
Мистер
Твистер —
Атаклы банкир,
Завод,
Пароход,
Газет хуҗасы —
Төшкәч нужасы,
«Англетер»гә
Керe кайтты шул:
Артында кызы —
Күтәргән маймыл,
Аннан карчыгы —
Күзлек кигән ул.
Бикле ишеккә
Мистер кагылды.
Коридор буйлап
Утлар кабынды.



Сәгать чыңлады
Унике тапкыр.
Швейцар торып
Ишекне ачты.
Озын мыегын
Сыйпап алды да
Килеп туктады
Алар алдына:

— Соңга калдыгыз!
Бая әйтелгән
Ике номерга
Кеше кертелгән.
Ерак-ерактан
Безгә съездга
Килде кунаклар.
Шушы кунаклар
Төштеләр монда,
Бөтен бүлмәләр
Алар кулында.



Кызы инәлде:
— Нишләргә инде,
Ардым шул хәтле?
Кунарга рәтле
Урын әгәр дә
Табылмый икән,
Сатып ал, әткәй,
Бер йорт
Шәһәрдә.


Мистер
Твистер,

Ачуы килеп,
Әйтте кызына:
— Чикаго түгел,
Кызым, бу сиңа.
Мин бик ризамын
Алай эшләргә,
Тик Ленинград
Сатмый читләргә!

Туры килер дип
Тышта йокларга,
Китеп үк бара
Ишеккә таба...

Аналы-кызлы
Истән аварга
Торганда гына,
Швейцар аларга
Бирмәкче булды
Үз кроватен:
— Ханымнар бире
Йокларлар ятып.

Ә мистер
Шуннан,
Ишек каршыннан,
Урындык алды.
Аркасын сөяп:
— Уф алла! — диеп,
Йокыга талды...




Совет номеры
«Англетер»нең
Бусагасында
Йоклап китәрен
Уйламагандыр
Элек ул һичбер,
Мистер
Твистер —
Булмыш министр,
Мистер
Твистер —
Миллионер...


11

Елмайды кинәт
Ул йокы катыш,
Күрә башлады
Гаҗәп
Кызык төш.
Күрә төшендә:
Караңгы төндә
Урамнар буйлап,
Йорт-җирсез сукбай
Булып ул үтә.
Оча самолет
Биектә — күктә,
Һәм күктән җиргә
Кук килеп төшә.


Ә Твистер аны
Барып кочаклый.
Кулларын кыса
Әллә ничаклы







Менеп ала да
Самолетына,
Ќаты иттереп
Ишеген яба.
Очып китәләр
Зәңгәр һавага.
Менә җитәләр
Америкага.
Мәрмәрдән салган
Йортлар —
Чикаго!
Ќартайган лакей
Кычкырды
Шундук:
— Америкада
Сезгә урын юк!
Имән ишекләр
Ябылды түрдә.




Уянып китсә,
Ул күрде үзен
«Англетер»дә.

Куркып уйланды:
— Нихәл итәрмен?..

Совет номеры
«Англетер»нең
Бусагасында
Төнен үткәрде
Мистер Твистер —
Булмыш министр,
Мистер Твистер —
Миллионер...
Пинжәген салып
Куйды ул шунда.
Җайлап тагын да
Талды йокыга.





12

Ә иртән иртүк
Бер малай килде:
Кулында тартма
Һәм щетка иде.
Коридор буйлап
Тотынды эшкә:
Ботинкаларны
Чистарта, сөртә —
Агын ак белән,
Карасын — кара,
Шиблетлар көлеп,
Ялтырап кала...

Шулай тын чакта,
Туп уйнап тыз-пыз,
Бүлмәдән чыкты
Бер малай, бер кыз
Чем-кара алар,
Торалар басып:
Негр малае — Том,
Дженни — апасы.

Күреп Твистерне,
Шундый җәллиләр:
— Урындыгында
Йоклый бит! — диләр. —
Мескен карт! — диләр...
— Итекләрен дә
Салмаган! — диләр.
Шундый җәллиләр,
Шундый җәллиләр...



— Дусларым! — диде
Щеткалы малай. —
Ул ярлы түгел,
Ул кеше бик бай!
Бүлмә алмады
Кичә ул монда —
Кара негрлар
Күрше торганга!
Ак тәне белән
Бик горурлана!
Шуңа күрә дә
Урындыгында
Туры киләдер
Аңа кунарга!..



— Ул менә шулай! —
Диде дә, малай
Тотынды эшенә —
Итек сөртергә:
Кызыл да сары,
Киңе дә тары,
Төрек һәм немец,
Швед, француз
Ботинкалары...
Куйган срокка
Чистартты барын,
Төрле төстәге
Шиблетлар парын.

Соңгы шиблетны
Ялтыратуга,
Күрде:
Чит кеше
Күзләрен уа.
Менә ул торды,
Алды портсигар.





Кинәт контордан
Чыкты швейцар:

— Булды! —
Диде ул. —
Сезгә урын бар.
Ике янәшә
Бик шәп номерлар —
Ванналы, заллы,
Фонтан,
Бакчалы.
Теләсәгез, мин
Хәзер күрсәтәм.
Тик алдан сезгә
Мин шуны әйтәм:

Уң як номерда —
Кытай вәкиле.
Сул як номерга
Негрлар килде.
Өске номерда —
Кунак — Һиндстан.
Аскы номерга
Килде Тунистан!..

Миллионер
Кулын
Чәбәкләп селки
Һәм инглизчә
Кычкыра:
— О'кей!
Куанычыннан
Күзе акая.
— Бирегез тизрәк,
Ачкычы кайда?

Маймылын,
Кызын
Култыкка кысып,
«Англетер»нең
Таныш баскычын
Атлады кызып —
Мистер
Твистер —
Булмыш министр,
Мистер
Твистер —
Миллионер.





60 тиен.
61 елнын 1 январеннан
6 тиен.

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1960